Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Каргалы авыл җирлеге Советы

2022 елның 25 феврале №19/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлеге Советының «Чистай муниципаль районы «Каргалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 22 июлендәге 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Чистай муниципаль районының «Каргалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының 2013 елның 22 июлендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Каргалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктта «әйләнә-тирә территория» төшенчәсен төшереп калдырырга;

1.2. 141.12 пунктның икенче абзацында «терлекчелек продуктлары» сүзләрен «терлекчелек продукциясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 141.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«141.3. Төнлә урамда йөргән вакытта хайваннар хуҗалары урамнарда һәм торак йортларның ишегалларында тынлыкны тәэмин итү өчен чаралар күрергә тиеш.»;

1.4. 144 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«144. Ауган һәм авария хәлендә булган агач үсентеләре җирләү урыннары территориясендә булу рөхсәт ителми.».

2. Әлеге карар, әлеге пункт үз көченә керүнең башка вакытлары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Әлеге карарның 1 пунктындагы 1.2 пунктчасы 2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең торак пунктлары территориясендә яисә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә (бастырып чыгарырга), шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми халыкка хәбәр ителгән (бастырып чыгарылган) көненнән үз көченә керә.

Каргалы авыл җирлеге
башлыгы М.А. Заһидуллин